# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Экологик экспертиза турында

Әлеге Закон экологик экспертиза өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала, Татарстан Республикасы гражданнарының уңайлы әйләнә-тирә табигать мохитенә конституциячел хокукларын гамәлгә ашыруга, Татарстан Республикасында әйләнә-тирә табигать мохитенә хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка төрле эшчәнлекнең уңайсыз йогынтыларын кисәтү юлы белән экологик иминлекне һәм табигатьтән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итүгә юнәлдерелә.

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Экологик экспертиза турындагы законнар

Экологик экспертиза турындагы законнар әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка төрле закон актларыннан гыйбарәт.

2 статья. Экологик экспертиза

Экологик экспертиза күз алдында тотылучы хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка төрле эшчәнлекнең экологик таләпләргә туры килү-килмәвен билгели һәм бу эшчәнлекнең әйләнә-тирә табигать мохитенә мөмкин булган уңайсыз йогынтыларын һәм экологик экспертиза объектын гамәлгә ашыруның шуларга бәйле рәвештә килеп чыккан социаль, икътисадый һәм башка төрле

нәтиҗәләрен кисәтү максатларында экологик экспертиза объектын гамәлгә ашыруның мөмкин булуын ачыклый.

3 статья. Экологик экспертиза төрләре

Татарстан Республикасында дәүләт экологик экспертизасы һәм җәмәгать экологик экспертизасы гамәлгә ашырыла.

4 статья. Экологик экспертиза принциплары

Экологик экспертиза түбәндәге принципларга нигезләнә:

күз алдында тотылучы теләсә нинди хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка эшчәнлекнең мөмкин булган экологик хәвефлелеге презумпциясе;

экологик экспертиза объектын гамәлгә ашыру турында карар кабул ителгәнче дәүләт экологик экспертизасын үткәрүнең мәҗбүрилеге;

экологик экспертизага тәкъдим ителгән мәгълүматның дөрес һәм тулы булуы;

экологик экспертиза бәяләмәләренең фәнни нигезләнгәнлеге, объективлыгы һәм законлылыгы;

хуҗалык эшчәнлегенең, башка төрле эшчәнлекнең әйләнә-тирә табигать мохитенә уңайсыз йогынтысын һәм аның нәтиҗәләрен бәяләүнең комплекслылыгы;

экологик экспертиза үткәргәндә экологик иминлек таләпләрен исәпкә алуның мәҗбүрилеге;

эксперт комиссияләре составында үз вәкаләтләрен башкарганда экологик экспертиза экспертларының бәйсезлеге;

экологик экспертизада катнашучыларның һәм экологик экспертизаны оештыру, үткәрү һәм аның сыйфаты белән кызыксынучы затларның җаваплылыгы;

хәбәрдарлык һәм җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу.

5 статья. Экологик экспертизаның мәҗбүрилеге

Хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек нәтиҗәсендә әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян килү мөмкин булса, шуларның проектлары һәм программалары буенча эшләрне гамәлгә ашыру һәм финанслау дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсеннән башка тыела.

## II бүлек. Экологик экспертиза өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, жирле үзидарә органнарының компетенциясе

6 статья. Экологик экспертиза өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы компетенциясе

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына түбәндәгеләр керә:

экологик экспертиза өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен билгеләү;

экологик экспертиза өлкәсендә закон чыгару юлы белән җайга салуны башкару;

экологик экспертиза өлкәсендә Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарны үтәүне тикшереп тору.

7 статья. Экологик экспертиза өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты компетенциясе

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карамагына экологик экспертиза өлкәсендә түбәндәгеләр керә:

экологик экспертиза өлкәсендә үз компетенциясе чикләрендә норматив-хокукый актлар кабул итү;

экологик экспертиза турындагы норматив-хокукый актларның Татарстан Республикасы министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары тарафыннан үтәлешен тикшереп тору, бу өлкәдә аларның эшчәнлеген җайга салу;

Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль үсеше буенча дәүләт программаларына экологик экспертизаның нәтиҗәләрен раслау;

Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль үсеше буенча дәүләт программаларына экологик экспертизаны финанслауны тәэмин итү;

республика әһәмиятендәге экологик экспертиза объектларына экологик экспертизалауны башкару өчен комиссияләр составын раслау, шулай ук Татарстан Республикасыннан читтә әйләнә-тирә табигать мохитенә тискәре йогынты ясау мөмкинлеге булган объектларга дәүләт экологик экспертиза комиссияләре составына утырышларда күзәтүчеләр буларак катнашу өчен экспертлар җибәрү;

экологик экспертиза өлкәсендә гражданнарның һәм юридик затларның хокукларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны башкару;

Татарстан Республикасы законнары белән Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карамагына кертелгән башка мәсьәләләрне хәл итү.

## 8 статья. Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы компетенциясе

Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы дәүләт экологик экспертизасын үткәрү буенча өстенлекле хокукка ия була һәм ул әлеге эшчәнлекне үзенең махсус вәкаләтле бүлекчәсе аша башкара.

Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

объектларга дәүләт экологик экспертизасы нәтиҗәләрен раслау, моңа Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль үсеше буенча дәүләт программаларының экспертизасы кертелми;

әгәр әлеге Законда башкасы каралмаган булса, хуҗалык эшчәнлеге һәм башка төрле эшчәнлек объектларына дәүләт экологик

экспертизасын оештыру һәм үткәрү, моңа дәүләт экологик экспертизасының эксперт комиссияләре составын барлыкка китерү һәм раслау да керә;

дәүләт экологик экспертизасы уңай бәяләмәсенең гамәлдә булу чорын һәм шартларын билгеләү;

үз вәкаләтләре чикләрендә билгеләнгән тәртиптә норматив-хокукый актларны һәм Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт экологик экспертизасын үткәрү өлешендә әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка төрле инструктив-методик документлар әзерләү һәм раслау;

дәүләт экологик экспертизасын үткәрүне норматив-техник, фәнни-методик, методологик тәэмин итү, фәнни тикшеренүләрне җайга салу, моңа экологик экспертиза турында законнарны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән норматив-техник документларның нигезен булдыру буенча семинарлар, конференцияләр үткәрү керә;

экологик экспертизаны мәгълүмати тәэмин итүне оештыру, шул исәптән киләчәктәге хуҗалык эшчәнлеге һәм башка төрле эшчәнлек турында, экологик экспертиза объектларын гамәлгә ашыру турында һәм бу эшчәнлекнең әйләнә-тирә табигать мохитенә йогынтысы турында белешмәләр банкын барлыкка китерү һәм алып бару;

табигатьтән файдалану өлкәсендә лицензияләнергә тиешле эшчәнлек төрләренең исемлеген әзерләүдә катнашу;

дәүләт экологик экспертизасын оештырганда һәм үткәргәндә әлеге Законның һәм экологик экспертиза өлкәсендәге башка норматив-хокукый актларның үтәлешен, шулай ук инспекция тикшеренүләрен уздырганда хуҗалык һәм бүтән эшчәнлек субъектларының дәүләт экологик экспертизасы таләпләрен үтәүләрен тикшереп тору;

дәүләт экологик экспертизасы экспертларының дәүләт реестрын алып бару;

экологик экспертиза мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары һәм җәмәгать оешмалары (берләшмәләре) белән үзара ярдәмләшеп эшләү.

Әлеге статьяның беренче өлешендә каралган вазыйфаларны башкару өчен Татарстан Республикасының дәүләт экологик

экспертизасы өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы түбәндәгеләргә хокуклы:

әйләнә-тирә табигать мохитенең торышы турында белешмәләр таләп итәргә һәм алырга, хуҗалык эшчәнлегенең, башка төрле эшчәнлекнең кешегә һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә йогынтысын бәяләү өлкәсендәге белешмәләр банкларына чыга алырга;

дәүләт идарәсе органнарыннан, башка дәүләт учреждениеләреннән һәм оешмаларыннан экологик экспертиза өлкәсендәге бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүматны түләүсез алырга;

экологик экспертиза өлкәсендә үз вәкаләтләрен башкару өчен кирәкле һәм законнарга каршы килмәүче бүтән гамәлләрне үз вәкаләтләре чикләрендә башкарырга.

Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

дәүләт экология экспертизасынын эксперт комиссияләре утырышларын үткәрү турында Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына, җирле үзидарә органнарына алдан хәбәр итәргә;

экологик экспертиза турындагы законнарнын бозылуы хакында прокуратура органнарына вакытында хәбәр итәргә;

дәүләт экология экспертизасын оештыруны һәм уздыруны җайга салучы норматив-техник, инструктив-методик һәм башка материалларны, шулай ук экологик экспертиза объектын характерлаучы материалларны (проектларны, сметаларны, нигезләүләрне һәм башкаларны) танышу өчен иҗтимагый экологик экспертиза ясаучы җәмәгать оешмаларына (берләшмәләренә) җибәрергә;

дәүләт экологик экспертизасын оештыруны һәм үткәрүне җайга салучы норматив-техник һәм инструктив-методик документларны дәүләт экологик экспертизасы үткәрү турында гариза биргән заказчыга танышу өчен җибәрергә;

булачак хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка төрле эшчәнлекнең экологик аспектлары буенча нигезләнгән тәкъдимнәрне кертүче җирле үзидарә органнарына, җәмәгать оешмаларына (берләшмәләренә) һәм

гражданнарга дәүләт экологик экспертизасы үткәргәндә бу тәкъдимнәрне карау турындагы материалларны җибәрергә;

экологик экспертиза турындагы законнарны бозуларда гаепле затларны җаваплылыкка тарту хакындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен тиешле материалларны әзерләргә һәм хокук саклау органнарына җибәрергә;

экологик экспертиза турындагы законнарнын нигезләмәләреннән килеп чыгучы башка таләпләрне үтәргә тиеш.

9 статья. Экологик экспертиза өлкәсендә дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары һәм җирле үзидарә органнары компетенциясе

Экологик экспертиза өлкәсендә халык депутатларының җирле Советлары компетенциясенә тиешле территориядә түбәндәгеләр керә:

җирле әһәмияттәге экология объектлары буенча, шулай ук табигатьтән файдаланучылар белән җирле администрацияләр арасындагы шартнамәләрнең проектлары буенча экологик экспертиза үткәрү һәм аның бәяләмәләрен раслау турындагы карарлар кабул итү;

законнарның һәм җирле әһәмияттәге экологик экспертиза объектларына карата үз карарларының үтәлешен тикшереп тору;

бу өлкәдә законнар нигезендә башка вәкаләтләр башкару.

Экологик экспертиза өлкәсендә район, шәһәр, шәһәрдәге район җирле администрацияләре компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

үз территорияләрендә гамәлгә ашырылырга тиеш хуҗалык эшчәнлеге һәм башка төрле эшчәнлек объектларына экологик экспертизада катнашу өчен яисә башка административ-территория берәмлегендә урнашкан объектның хуҗалык эшчәнлеге үзенә караган территориядәге әйләнә-тирә мохиткә уңайсыз йогынты ясау ихтималы булган очракларда эксперт комиссияләре составына экспертлар җибәрү;

район (шәһәр, шәһәрдәге район) территориясендә киләчәктә әйләнә-тирә табигать мохитенә уңайсыз йогынты ясау ихтималы булган хуҗалык эшчәнлеге һәм башка төрле эшчәнлек турында Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органына мәгълүмат бирү;

экологик экспертиза турындагы законнарны бозу хакында прокуратура органнарына, Татарстан Республикасынын әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органына һәм Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына мәгълүмат бирү;

законнар нигезендә экологик экспертиза өлкәсендә башка вәкаләтләр башкару.

Әлеге статьяның беренче һәм икенче өлешендә каралган вәкаләтләрне башкару өчен дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары гамәлгә ашырылулары әйләнә-тирә мохиткә уңайсыз йогынты ясарга мөмкин булган экологик экспертиза объектлары турында мәгълүмат алырга хокуклы.

Экологик экспертиза өлкәсендә җирле үзидарә органнары компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

экологик экспертиза үтәргә тиешле хуҗалык эшчәнлеге һәм башка төрле эшчәнлек турында халык арасында җәмәгатьчелек фикер алышулары оештыру, сорашып белешүләр, референдумнар уздыру;

халыкның таләп итүе буенча иҗтимагый экологик экспертиза оештыру.

Үз вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

гамәлгә ашырылулары тиешле җирле үзидарә территориясе чикләрендә әйләнә-тирә мохиткә уңайсыз йогынты ясарга мөмкин булган экологик экспертиза объектлары турында кирәкле мәгълүматны, шулай ук дәүләт экология экспертизасын үткәрү һәм иҗтимагый экологик экспертиза нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны тиешле дәүләт органнарыннан алырга;

күздә тотылган хуҗалык эшчәнлегенең, башка төрле эшчәнлекне гамәлгә ашыруның экологик аспектлары буенча дәлилләнгән тәкъдимнәрне Татарстан Республикасынын экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органына язма рәвештә җиткерергә.

## III бүлек. Дәүләт экология экспертизасы

10 статья. Дәүләт экология экспертизасы

Дәүләт экология экспертизасы әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасының экологик экспертизасы өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә оештырыла һәм уздырыла.

11 статья. Дәүләт экология экспертизасы объектлары

Дәүләт экология экспертизасын мәҗбүри үтәргә тиешлеләр:

Татарстан Республикасының норматив һәм норматив булмаган хокукый актларының, әйләнә-тирә табигать мохитенә уңайсыз йогынты ясарлык хуҗалык эшчәнлеген һәм башка төрле эшчәнлекне җайга салучы норматив-техник һәм инструктив-методик документларның проектлары;

Татарстан Республикасы территориясендәге җитештерү көчләренең үсешен һәм аларны урнаштыруны фаразлауларны әзерләү буенча дәүләт хакимияте органнары раслый торган проектлар, шул исәптән:

а) гамәлгә ашырылулары әйләнә-тирә табигать мохитенә уңайсыз йогынты ясарга мөмкин булган комплекслы һәм максатчыл социаль-икътисадый, фәнни-техник һәм башка төрле программаларның проектлары;

б) Татарстан Республикасы халык хуҗалыгы тармакларының, шул исәптән сәнәгать, авыл хуҗалыгы, төзелеш һәм транспорт үсеше схемаларының;

в) Татарстан Республикасының җитештерүче көчләрен урнаштыру, табигатьтән файдалану һәм территориаль яктан оештыру буенча генераль схемаларның;

г) табигатьне саклау һәм табигатьтән файдалану буенча территориаль комплекслы схемаларның;

д) Татарстан Республикасында гамәлгә ашырылучы инвестиция һәм хосусыйлаштыру программаларының;

территорияләргә республика һәм жирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләренең, экологик бәла-каза зонасы һәм гадәттән тыш хәл зонасының хокукый статусын нигезләүче һәм шушы территорияләрнең кишәрлекләрен комплекслы экологик тикшеренү буенча материаллар;

продукцияне бүлешү турындагы килешүне нигезләүче документлар, концессион шартнамәләр, шулай ук табигый байлыкларны һәм (яисә) җитештерү калдыкларын куллануны күз алдында тотучы башка шартнамәләр;

шәһәр төзелеше документларының барлык төрләре, шул исәптән:

а) административ-территория берәмлекләренең район планлаштыруы схемалары һәм проектлары;

б) шәһәрләрнең, башка торак пунктларының генераль планнары һәм аларның схемалары;

в) шәһәр һәм поселокларның, шулай ук авыл җирләренең административ сызыгы проектлары;

г) жирле үзидарә органнарына караган территорияләрнең, шулай ук селитеб, сәнәгати, ял итү һәм башка вазыйфаи зоналарның генераль планнары;

д) иҗтимагый үзәкләрнең, торак районнарының, шәһәр магистральләренең детальле планлаштыру проектлары;

е) шәһәрләрнең һәм башка торак пунктларының кварталларын һәм кишәрлекләрен кору проектлары;

геологик-разведка, казылмалар чыгару һәм эшләрнең башка төрләрен башкару нәтиҗәсендә бозылган җирләрне рекультивацияләү проектлары;

смета хакларына, нинди ведомствога буйсынуларына һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан хуҗалык эшчәнлеге объектларын, шулай ук Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясенең уртак карамагындагы хуҗалык эшчәнлеге объектларын төзүне, реконструкцияләүне, киңәйтүне, техник коралландыруны, консервацияләүне һәм ябуны техник-икътисадый нигезләүләр һәм аларның проектлары, шул исәптән чит ил инвестицияләре булган оешмаларны төзү материаллары;

су, урман, җир байлыкларын һәм башка табигый байлыкларны саклау һәм куллану схемаларының проектлары, бу өлкәдәге бүтән проект документлары, шул исәптән урман корылышы, җирдән файдалану, аучылыкны оештыру проектлары;

территорияләрнең вазыйфаи статусын, алардан файдалану төрен һәм характерын үзгәртү документлары, шул исәптән урман фонды җирләрен башка категория җирләренә күчерүне нигезләүче материаллар;

әйләнә-тирә табигать мохитенә йогынты ясарлык эшчәнлек башкару өчен лицензия алуны нигезләүче материаллар;

халыкара шартнамәләр, контрактлар, килешүләр проектларының экологик нигезләүләре;

яңа техниканың , технологияләрнең һәм әйләнә-тирә табигать мохитенең торышына йогынты ясарлык материалларның һәм әйберләрнең, шул исәптән чит илләрдән сатып алына торганнарының да, экологик таләпләргә туры килүен раслаучы документлар;

әлеге статьяда санап үтелгән һәм элегрәк үткәрелгән дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсен алган дәүләт экологик экспертиза объектлары, түбәндәге очракларда:

а) элегрәк үткәрелгән дәүләт экологик экспертизасының кисәтүләре нигезендә дәүләт экологик экспертизасы объектларын эшләп бетергәндә;

б) табигатьтән файдалану шартларын үзгәрткәндә яисә экологик экспертиза объектын гамәлгә ашыруның күз алдында тотылучы зонасында әйләнә-тирә табигать мохитенең торышын асылдан үзгәрткәндә;

в) дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсен алганнан соң документларга үзгәрешләр керткәндә;

г) дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсен алган документлардан тайпылып, дәүләт экологик экспертиза объектын гамәлгә ашырганда һәм (яисә) күрсәтелгән документларга үзгәрешләр керткәндә;

д) дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе гамәлдә булу вакыты узганда;

гамәлгә ашырылулары әйләнә-тирә табигать мохитенә йогынты ясарлык хуҗалык эшчәнлеген һәм башка төрле эшчәнлекне нигезләүче һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнүче документларның бүтән төрләре.

12 статья. Дәүләт экологик экспертизасын үткәрү шартлары

Дәүләт экологик экспертизасы, шул исәптән кабат үткәрелүчесе дә, заказчы биргән материалларның рәвеше һәм эчтәлеге әлеге Закон таләпләренә, дәүләт экологик экспертизасы үткәрүнең билгеләнгән тәртибенә туры килгәндә һәм түбәндәге материаллар булганда үткәрелә:

а) әлеге Законның 11 статьясы нигезендә билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла торган күләмдә һәм дәүләт экологик экспертизасы үтәргә тиешле хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка төрле эшчәнлекнең әйләнә-тирә табигать мохитенә йогынты ясавына бәя бирүче дәүләт экологик экспертизасы узарга тиешле материаллары булган документлар;

б) дәүләт экологик экспертизасы объекты буенча уңай бәяләмәләр һәм (яисә) дәүләт күзәтүе һәм тикшереп тору органнарының аларны килештерү буенча документлары, шулай ук дәүләт экологик экспертиза объектын дәүләт идарәсе органнары караган очракта уңай бәяләмәләр (килештерү документлары) һәм үткәрелгән очракта иҗтимагый экологик экспертиза бәяләмәләре;

в) җирле үзидарә органнары оештырган фикер алышуларда дәүләт экологик экспертиза объекты буенча гражданнар һәм җәмәгать оешмалары (берләшмәләре) белән фикер алышуларның материаллары.

Дәүләт экологик экспертизасы үтәргә тиешле документларның заказчысы шушы экспертиза үткәрүгә бәйле чыгымнарны тулысынча һәм әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә алдан түләсә генә, дәүләт экологик экспертизасы үткәрелә.

Дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә бәйле чыгымнарны түләү буенча өстенлекле ташламалар Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаган тәртиптә биреләләр.

Дәүләт экологик экспертизасын үткәрүне башлау вакыты аның өчен түләнгәннән соң һәм кирәкле документлар тулысынча кабул итеп алынганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча билгеләнә.

Дәүләт экологик экспертизасы объектының катлаулылыгын исәпкә алып, тиешле тәртиптә расланган норматив документлар

нигезендә билгеләнгән дәүләт экологик экспертизасын үткәрү вакыты 6 айдан артмаска тиеш.

Дәүләт экологик экспертизасын әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасынын экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан конкрет объектка экологик экспертиза үткәрү өчен оештырылган эксперт комиссиясе үткәрә.

Әлеге Законның 16 статьясы таләпләренә җавап бирерлек дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсе дәүләт экологик экспертизасын үткәрү нәтиҗәсе була.

Әгәр әлеге Законда башкасы каралмаган булса, дәүләт экологик экспертизасын кабат үткәрү суд органнары карары нигезендә башкарыла.

<u>13 статья.</u> Дәүләт экологик экспертизасының эксперт комиссиясе

Дәүләт экологик экспертизасынын эксперт комиссиясен оештыруны, анын җитәкчесен, җаваплы секретарен билгеләп куюны һәм экспертларның персональ составын раслауны да кертеп, Татарстан Республикасынын экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы гамәлгә ашыра. Республика әһәмиятендәге хуҗалык эшчәнлеге һәм башка төрле эшчәнлек объектларына экологик экспертиза үткәрү өчен комиссия составы Татарстан Республикасынын Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

Дәүләт экологик экспертизасынын эксперт комиссиясе составына, экспертлардан тыш, үз ризалыклары буенча штаттан тыш экспертлар да кертелергә мөмкин һәм Татарстан Республикасынын экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органынын норматив-хокукый актларында билгеләнгән очракларда, дәүләт экологик экспертизасының экспертлары буларак, ул органның һәм анын бүлекчәләренең штаттагы хезмәткәрләре дә кертелергә мөмкин.

<u>14 статья.</u> Дәүләт экологик экспертизасы эксперты

Каралучы мәсьәлә буенча фәнни һәм (яисә) гамәли белемнәре булган һәм Татарстан Республикасының экологик экспертиза

өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы карары нигезендә җәлеп ителүче белгеч дәүләт экологик экспертизасы эксперты булырга мөмкин.

Заказчы вәкиле, шулай ук дәүләт экологик экспертизасы үтәргә тиешле документларны әзерләүче, шулай ук шушы заказчы һәм (яисә) әзерләүче белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә яисә башка төрле шартнамәчел мөнәсәбәтләрдә торучы физик затлар һәм предприятиеләрнең, оешмаларның урындагы затлары дәүләт экологик экспертизасы эксперты була алмый.

Дәүләт экологик экспертизасы эксперты аны үткәрүдә әлеге Закон нигезендә катнаша.

Эксперт, шулай ук штаттан тыш эксперт тулаем бәяләмә буенча яисә аның өлешләре буенча үзенчәлекле фикерен белдерергә хаклы, мондый фикер дәүләт экологик экспертиза бәяләмәсенә кушып бирелә һәм аның аерылмас өлеше була.

Экспертның хокуклары һәм бурычлары, шул исәптән иҗтимагый экологик экспертизаның вәкаләтләре күләме дә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Дәүләт экология экспертизасы эксперты хокуклары административ һәм суд тәртибендә якланырга тиеш, ә аларны бозуда гаепле затлар юридик җаваплылыкка тартылалар.

Дәүләт экология экспертизасында катнашучы штат хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Дәүләт экологик экспертизасынын штаттан тыш экспертлары хезмәте өчен түләү Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан шартнамәчел (контракт) нигездә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә башкарыла.

## 15 статья. Дәүләт экологик экспертизасының эксперт комиссиясе җитәкчесе

Дәүләт экологик экспертизасының эксперт комиссиясе җитәкчесе, кагыйдә буларак, Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы карары белән билгеләнеп

куела. Эксперт комиссиясе җитәкчесе үз эшчәнлеген әлеге Закон һәм дәүләт экологик экспертизасын үткәрү йөкләмәсе нигезендә гамәлгә ашырырга тиеш.

Дәүләт экологик экспертизасының эксперт комиссиясе җитәкчесе:

конкрет объект буенча дәүләт экологик экспертизасын сыйфатлы итеп уздыруны тәэмин итә;

экологик экспертиза өлкәсендәге законнарның таләпләре, нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә шушы эксперт комиссиясенең җыелма бәяләмәсен әзерләүне оештыра.

<u>16 статья.</u> Дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсе

Дәүләт экологик экспертизасының эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән, дәүләт экологик экспертизасы узарга тиешле хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә табигать мохитенә тәэсир итү мөмкинлеге турында һәм дәүләт экологик экспертизасы объектын гамәлгә ашыру мөмкинлеге турында нигезле нәтиҗәләре булган, күрсәтелгән эксперт комиссиясенең исемлек составындагы квалификацияле күпчелек тавышы белән хупланган документ дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсе була.

Дәүләт экологик экспертизасының эксперт комиссиясе әзерләгән бәяләмә җитәкче, җаваплы секретарь һәм күрсәтелгән комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм аларның ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый.

Дәүләт экологик экспертизасының эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән бәяләмәгә күрсәтелгән комиссия кабул иткән бәяләмә белән яисә аның бер өлеше белән килешмәгән экспертларның аерым дәлилле фикерләре кушылып бирелә.

Дәүләт экологик экспертизасының эксперт комиссиясе тарафыннан әзерләнгән бәяләмә Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы раслаганнан соң дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсе статусын ала.

Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары проектларыннан гайре, әлеге Законның 11 статьясында күрсәтелгән

объектлар буенча дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсе уңай һәм тискәре булырга мөмкин.

Дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе - дәүләт экологик экспертизасы объектын финанслауның һәм гамәлгә ашыруның катгый шартларының берсе. Дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе дәүләт экологик экспертизасының эксперт комиссиясен тәшкил иткән Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан билгеләнгән чор дәвамында юридик көчкә ия була.

Дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе түбәндәге очракларда юридик көчен югалта:

элек уздырылган дәүләт экологик экспертизасы искәрмәләре буенча дәүләт экологик экспертизасы объектын эшләп бетергәндә;

Татарстан Республикасының әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан табигатьтән файдалану шартлары үзгәртелгәндә;

дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсен алганнан соң проект документларына һәм башка төрле документларга үзгәрешләр керткәндә;

дәүләт экологик экспертизасы объектын дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсен алган документлардан читкә тайпылып гамәлгә ашырганда һәм (яисә) күрсәтелгән документларга үзгәрешләр керткәндә;

дәүләт экологик экспертизасы уңай бәяләмәсенең гамәлдә булу вакыты чыкканда.

Дәүләт экологик экспертизасының тискәре бәяләмәсенең хокукый нәтиҗәләре дәүләт экологик экспертизасы объектыннан файдаланудан тыю була.

Дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсе заказчыга җибәрелә. Тиешле тикшереп тору функцияләрен гамәлгә ашыру өчен дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсе турындагы мәгълүмат дәүләт идарәсенең тиешле органнарына, дәүләт экологик экспертиза объектын финанслаучы банк оешмаларына, ә закон бозылган очракта хокук саклау органнарына җибәрелә.

Дәүләт экологик экспертизасының тискәре бәяләмәсе алынган очракта заказчы материалларны күрсәтелгән бәяләмәдә бәян ителгән искәрмәләрне исәпкә алып эшкәртү шарты белән дәүләт экологик экспертизасына кабат тапшырырга хокуклы.

Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары проектлары буенча дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсе бу актларны кабул итүче дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары тарафыннан карала.

Халыкара шартнамә проектына дәүләт экологик экспертизасын мәҗбүри уздыру таләпләрен үтәмәү аны гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез була.

Дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсе буенча бәхәсләр суд тәртибендә каралырга мөмкин.

## IV бүлек. Экологик экспертиза өлкәсендә гражданнарның һәм иҗтимагый оешмаларның (берләшмәләрнең) хокуклары. Иҗтимагый экологик экспертиза

### 17 статья. Экологик экспертиза өлкәсендә гражданнарның һәм иҗтимагый оешмаларның (берләшмәләрнең) хокуклары

Экологик экспертиза өлкәсендә гражданнар һәм иҗтимагый оешмалар түбәндәгеләргә хокуклы:

шушы территориядә яшәүче халыкның экологик мәнфәгатьләренә кагылучы хуҗалык эшчәнлегенә һәм башка төрле эшчәнлеккә әлеге Закон нигезендә иҗтимагый экологик экспертиза уздыру турында тәкъдимнәр кертергә;

күздә тотылучы хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка төрле эшчәнлекнең экологик аспектлары буенча дәлилләнгән тәкъдимнәрне язма рәвештә Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органына җибәрергә;

экологик экспертизаның конкрет объектларына дәүләт экологик экспертизасы уздыру нәтиҗәләре турында экологик экспертиза өлкәсендә Татарстан Республикасының махсус вәкаләтле дәүләт органыннан мәгълүмат алырга;

экологик экспертиза өлкәсендә законнарга каршы килми торган бүтән гамәлләр башкарырга.

Эксперт комиссиясе тарафыннан дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсе әзерләнгәндә һәм дәүләт экологик экспертизасы объектын тормышка ашыру турында карар кабул иткәндә, дәүләт экологик экспертизасының эксперт комиссиясенә җибәрелгән иҗтимагый фикерне чагылдыручы материаллар каралырга тиеш.

18 статья. Иҗтимагый экологик экспертиза

Иҗтимагый экологик экспертиза гражданнар һәм иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) инициативасы, шулай ук җирле үзидарә органнары инициативасы буенча, эшчәнлекләренең төп юнәлеше аларның уставлары нигезендә әйләнә-тирә табигать мохитен саклауга, шул исәптән экологик экспертизаны оештыруга һәм уздыруга юнәлдерелгән һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән иҗтимагый оешмалар тарафыннан оештырыла һәм уздырыла.

19 статья. Иҗтимагый экологик экспертиза объектлары

Дәүләт серен һәм закон белән саклануччы башка серне тәшкил итүче объектлардан гайре, әлеге Законның 11 статьясында күрсәтелгән объектларга карата иҗтимагый экологик экспертиза уздырылырга мөмкин.

20 статья. Иҗтимагый экологик экспертиза уздыру

Иҗтимагый экологик экспертиза дәүләт экологик экспертизасы уздырылуга бәйсез рәвештә шул ук экологик экспертиза объектларына да уздырылырга мөмкин.

Иҗтимагый экологик экспертизаны гамәлгә ашыручы иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләргә хокуклы:

экологик экспертиза узарга тиешле документларны заказчыдан әлеге Законның 12 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән күләмдә алырга;

дәүләт экологик экспертизасын уздыруга таләпләрне билгели торган норматив-техник документлар белән танышырга;

дәүләт экологик экспертизасының эксперт комиссияләре утырышларында һәм иҗтимагый экологик экспертиза бәяләмәләре буенча алар оештыра торган фикер алышуларга үз вәкилләре аша күзәтүчеләр буларак катнашырга.

Иҗтимагый экологик экспертиза уздыру өчен җәлеп ителүче экспертларга әлеге Законда билгеләнгән таләпләр куела.

<u>21 статья.</u> Иҗтимагый экологик экспертиза уздыру шартлары

Иҗтимагый экологик экспертиза иҗтимагый оешмаларның (берләшмәләрнең) аны уздыру турындагы гаризалары дәүләт теркәвенә алынса гына гамәлгә ашырыла. Экологик экспертиза объектына экологик экспертиза уздыру турында ике һәм берничә иҗтимагый оешмадан (берләшмәдән) гариза булганда бердәм эксперт комиссиясе төзү рөхсәт ителә.

Җирле үзидарә органы иҗтимагый экспертиза уздыру турында гариза алынганнан соң җиде көн эчендә аны теркәргә яисә теркәүдән баш тартырга тиеш. Иҗтимагый экологик экспертиза уздыру турындагы гаризаны билгеләнгән вакыт эчендә теркәү кире кагылмаса, ул теркәлгән дип санала.

Иҗтимагый экологик экспертиза уздыру турында иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) гаризасында уставта каралган эшчәнлекнең исеме, юридик адресы, үзенчәлеге, иҗтимагый экологик экспертизаның эксперт комиссиясе составы турында белешмәләр, иҗтимагый экологик экспертиза объекты турында белешмәләр, иҗтимагый экологик экспертиза уздыру вакытлары күрсәтелергә тиеш.

Иҗтимагый экологик экспертизаны оештыручы иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) аны уздыруның кайчан башлануы һәм аның нәтиҗәләре турында халыкка хәбәр итәргә тиеш.

22 статья. Иҗтимагый экологик экспертиза уздыру турындагы гаризаны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту

Иҗтимагый экологик экспертиза уздыру турындагы гаризаны дәүләт теркәвенә алудан түбәндәге очракларда баш тартырга мөмкин, әгәр:

экологик экспертиза объектына карата элек ике мәртәбә иҗтимагый экологик экспертиза уздырылган булса;

дәүләт серен, коммерция серен һәм (яисә) закон белән сакланучы башка төрле серне тәшкил итә торган объектка карата иҗтимагый экологик экспертиза уздырылса;

оешманы (берләшмәне) дәүләт теркәвенә алу билгеләнгән тәртипкә туры килмәсә;

иҗтимагый экологик экспертизаны оештыручы һәм уздыручы иҗтимагый оешманың (берләшмәнең) уставы әлеге Законның 18 статьясы таләпләренә туры килмәсә;

иҗтимагый экологик экспертиза уздыру турындагы гаризаның эчтәлегенә карата әлеге Законның 21 статьясында каралган таләпләр үтәлмәсә.

Әлеге статьяда китерелгән иҗтимагый экологик экспертиза уздыру турындагы гаризаны дәүләт теркәвенә алудан баш тарту өчен нигезләүләр исемлеге хәлиткеч була.

Җирле администрацияләрнең урындагы затлары иҗтимагый экологик экспертиза уздыру турындагы гаризаны дәүләт теркәвенә алудан законсыз баш тарткан өчен җаваплы булалар.

23 статья. Иҗтимагый экологик экспертиза бәяләмәсе

Иҗтимагый экологик экспертиза бәяләмәсе Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органына, иҗтимагый экологик экспертиза уздырылырга тиешле документлар заказчысына, экологик экспертиза объектларын гамәлгә ашыру турында карар кабул итүче органнарга һәм башка кызыксынучы затларга җибәрелә.

Иҗтимагый экологик экспертиза җәмәгать оешмасының шуңа вәкаләтле урындагы (сайлаулы) заты тарафыннан расланганнан соң, экспертиза нәтиҗәләрен экологик экспертиза өлкәсендәге шуңа вәкаләтле махсус дәүләт органы белән килештергәннән соң юридик көченә керә.

Иҗтимагый экологик экспертиза бәяләмәсен раслаганнан соң иҗтимагый экологик экспертиза җитәкчесенә һәм әгъзаларына әлеге Законның 28 статьясының гамәли көче кагыла.

Иҗтимагый экологик экспертиза бәяләмәсе матбугатта басып чыгарылырга мөмкин.

## V бүлек. Экологик экспертиза узарга тиешле документлар заказчысының хокуклары һәм бурычлары

### 24 статья. Экологик экспертиза узарга тиешле документлар заказчысының хокуклары

Экологик экспертиза узарга тиешле документлар заказчылары түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органыннан бу заказчыларның мәнфәгатьләренә кагылучы экологик экспертиза уздыру вакытлары турында мәгълүмат алырга;

Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органыннан танышу өчен дәүләт экологик экспертизасы уздыру турында норматив-техник һәм күрсәтмә-ысуллый документлар алырга;

дәүләт экологик экспертизасын уздырганда ясалган хокук бозуларны бетерүне таләп итеп, Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органына мөрәҗәгать итәргә;

дәүләт экологик экспертизасы объектларына карата язма рәвештә яисә телдән аңлатмалар, искәрмәләр, тәкъдимнәр бирергә;

дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсе буенча бәхәсләрне суд тәртибендә хәл итәргә;

экологик экспертиза турындагы законнарны белә торып бозып китергән зыян хакында судка дәгъва белдерергә.

25 статья. Экологик экспертиза узарга тиешле документлар заказчыларының бурычлары

Экологик экспертиза узарга тиешле документлар заказчылары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

экологик экспертиза үткәрү, шул исәптән дәүләт экологик экспертизасын кабат үткәрү өчен әлеге Законның 11, 12 һәм 19 статьялары таләпләре нигезендә документлар бирергә;

дәүләт экологик экспертизасын уздырган өчен түләргә;

Татарстан Республикасының экологик экспертиза өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органына һәм экологик экспертиза уздыруны оештыручы иҗтимагый оешмаларга (берләшмәләргә) экологик экспертиза объектларына кагылышлы тиешле материалларны, белешмәләрне, исәп-хисапларны, өстәмә эшләнмәләрне тапшырырга;

дәүләт экологик экспертизасының унай бәяләмәсен алган документлар нигезендә хуҗалык эшчәнлеген һәм башка төрле эшчәнлекне гамәлгә ашырырга;

дәүләт экологик экспертизасы объектын гамәлгә ашыруны финанслауны башлау өчен банк оешмаларына дәүләт экологик экспертизасы бәяләмәсе нәтиҗәләре турында белешмәләр бирергә.

## VI бүлек. Экологик экспертизаны финанслау

26 статья. Дәүләт экологик экспертизасын финанслау

Объектларга дәүләт экологик экспертизасын, шул исәптән аны кабат уздыруны финанслау дәүләт экспертизасы узарга тиешле документлар заказчысы акчалары исәбенә гамәлгә ашырыла.

Финанс чаралары дәүләт экологик экспертизасы узарга тиешле документлар заказчылары тарафыннан Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә һәм Татарстан Республикасы

Министрлар кабинеты раслаган тәртиптә дәүләт экологик экспертизасы уздыру өчен кулланыла.

27 статья. Иҗтимагый экологик экспертизаны финанслау

Иҗтимагый экологик экспертизаны финанслау иҗтимагый оешмаларның (берләшмәләрнең) үз акчалары һәм башка фондлар, гражданнарның һәм оешмаларның ирекле рәвештә кертелгән акчалата максатчан кертемнәре, шулай ук җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә бүленүче башка акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

## VII бүлек. Экологик экспертиза турында Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен җаваплылык

28 статья. Экологик экспертиза турында Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен җаваплылык

Экологик экспертиза турында Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен юридик һәм физик затлар законнар нигезендә җаваплы булалар.

Җаваплылыкка тарту гаепле затларны җибәрелгән хокук бозуларны бетерүдән һәм китерелгән зыянны түләүдән азат итми.

## VIII бүлек. Экологик экспертиза өлкәсендәге бәхәсләрне хәл итү

29 статья. Экологик экспертиза өлкәсендәге бәхәсләрне хәл итү

Экологик экспертиза өлкәсендәге бәхәсләр законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

IX бүлек. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре

30 статья. Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре

Әгәр Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсе белән экологик экспертиза өлкәсендә әлеге Закондагыдан үзгәрәк кагыйдәләр каралмаган булса, халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

X бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре

31 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү тәртибе турында

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты өч ай эчендә:

норматив-хокукый актларны әлеге Законга яраклаштырырга;

әлеге Законны гамәлгә ашыру өчен кирәкле норматив-хокукый актларны кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 1 декабре
№ 2471